РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» март 2020 ел г. Альметьевск № 357

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 1341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 6 маендагы 380 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 28 августындагы 714 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 ноябрендәге 1008 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 30 декабрендәге 1278 номерлы карарлары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 сентябрендәге 1341 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге 1149 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче кушымтасында:

Зак. № 305-2000

1.1.1. «Әйдәүче звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары «һөнәри квалификация төркеме» бүлегенең 2 бүлегенең 2.2 пунктындагы таблицаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| **«Әйдәүче звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары «һөнәри квалификация төркеме»** | | |
|---|---|---|
| Библиотекарь | 10 500 | 13 000»; |
| Тавыш операторы | | |
| Әйдәп баручы китапханәче | | |
| Рәссам-декоратор | | |
| Баш китапханәче | | |

1.1.2. 5 бүлекнең 5.2 пунктындагы сигезенче абзацында «300» санын «550» санына алмаштырырга;

1.1.3. 6 бүлекнең 6.15 пунктындагы 6.15.11 пунктчасының бишенче һәм җиденче абзацларыннан «һәм төп вазыйфасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.4. 6 бүлекнең 13 нче таблицасының 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.3 - 2.5 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.3. | Әйдәп баручы китапханәче | 42 |
| 2.4. | Рәссам-декоратор | 45 |
| 2.5. | Баш китапханәче | 45»; |

1.2. Карарның 2 нче кушымтасында:

1.2.1. 3 бүлекнең 3.3 пунктындагы 3.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка җитәкчеләренә, укытучы - дефектологларга, укытучы - логопедларга, педагог - психологларга, кече тәрбиячеләргә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар (тәрбияләнүчеләр) белән турыдан-туры эшләүче тәрбияче ярдәмчеләренә:

гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәге төркемнәрне дә кертеп):

ике айдан өч яшькә кадәр - 15 бала;

өч яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр-20 бала;

гаилә белеме формасындагы төркемнәрдә -7 бала;

Өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен компенсацияләү юнәлешләре төркемнәрендә:

сөйләмнәре авыр булган балалар өчен - 6 бала һәм 10 бала;

Өч яшьтән өлкәнрәк яшьтәге сөйләмнәрендә фонетик-фонематик бозу очраклары булган балалар өчен - 12 бала;

саңгырау балалар өчен - ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

начар ишетүче балалар өчен-6 бала һәм 8 бала;

сукыр балалар өчен - ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

начар күрүче балалар, амблиопияле, кылый күзле балалар өчен-6 бала һәм 10 бала;

терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен-6 бала һәм 8 бала;

психик үсешләрендә тоткарлык булган балалар, акылга зәгыйфь балалар өчен-6 бала һәм 10 бала;

акыл ягыннан уртача дәрәҗәдә, авыр дәрәҗәдә артта калган балалар өчен, өч яшьтән өлкәнрәкләр арасында - 8 бала;

аутистик спектры бозылган балалар өчен - ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

катлаулы дефектлары булган балалар өчен (физик һәм (яисә) психик үсештә ике яки аннан да күбрәк җитешсезлек ярашуы булган) - ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

катнаш юнәлештәге төркемнәрдә:

Өч яшькә кадәрге яшьтә - 10нан артык бала түгел, шул исәптән сәламәтлеге чикләнгән 3 бала;

өч яшьтән өлкәнрәк:

10нан да артмаган бала, шул исәптән 3 саңгырау бала, яки сукыр бала, яки терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, яки акыл ягыннан уртача дәрәҗәдә, авыр дәрәҗәдә артта калган балалар, яки аутистик спектры бозылган балалар, яки катлаулы дефектлы балалар;

15 тән артык бала, шул исәптән 4 начар күрүче һәм (яки) амблиопия һәм (яки) кылый күзле булган балалар, яки начар ишетүче балалар, яки сөйләмнәре авыр булган балалар, яки җиңел дәрәҗәдә акыл ягыннан артта калган балалар;

17дән артык бала, шул исәптән психик үсеш тоткарланган 5 тән дә артык булмаган бала;

өч яшькә кадәрге һәм аннан өлкәнрәк балалар өчен сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә:

туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала туры килә;

еш авыручы балалар һәм махсус савыктыру чаралары комплексы кирәк булган башка категориядәге балалар өчен - 10 бала һәм 15 бала туры килә»;

1.2.2. 3 бүлекнең 3.3 пунктындагы 3.3.2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2.3. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 5.12.11 пунктчасының бишенче һәм җиденче абзацларыннан «һәм төп вазыйфасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Карарның 3 нче кушымтасында:

1.3.1. 4 бүлекнең 4.2 пунктындагы 1 нче таблицадагы 55 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «55. | Спорт аэробикасы | 1,5 | 2,2 | 4,2 | 5,0 | 6,7 | 8,6 | 11,1 | 14,3 | 20,0 | 30,0 | 40,0»; |

1.3.2. 4 бүлекнең 4.2 пунктындагы 1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 81 нче пунктны өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «81. | Акробатик рок-н-ролл | 1,5 | | 1,5 | 2,2 | 3,7 | 4,4 | 6,9 | 8,3 | 11,1 | 22,2 | 22,2 | 50,0» |

1.3.3. 4 бүлекнең 4.2 пунктындагы 2 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 81 нче пунктны өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «81. | Акробатик рок-н- | 4 | 4 | 6 | 8 | 8 | 10 | 12 | 12 | 16 | 16 | 18»; |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ролл | | | | | | | | | | |

1.3.4. 4 бүлекнең 4.2 пунктындагы 3 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 81 нче пунктны өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «81. | Акробатик рок-н-ролл | 15 | 15 | 15 | 12 | 10 | 8 | 8 | 6 | 4 | 4 | 2»; |

1.3.5. 4 бүлекнең 4.2 пунктындагы 7 нче таблицадагы «Республика чемпионаты» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы чемпионаты | 1 | 10,0 | 3,5 | 5,0 | 1,8». |

1.3.6. 6 бүлекнең 6.8 пунктындагы 6.8.11 пунктчасының бишенче һәм җиденче абзацларыннан «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга.;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы түбәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә:

2020 елның 1 гыйнварыннан - 1.2.1., 1.2.2 пунктчаларына кагылышлы үзгәрешләр өчен;

2019 елның 6 маеннан - 1.3.1., 1.3.2, 1.3.3, 1.3.4, 1.3.5 пунктчаларына кагылышлы үзгәрешләр өчен;

2019 елның 28 августыннан - 1.1.1., 1.1.4 пунктчаларына кагылышлы үзгәрешләр өчен;

2019 елның 1 сентябреннән - 1.1.2., 1.1.3, 1.2.3, 1.3.6 пунктчаларына кагылышлы үзгәрешләр өчен.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ